ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унбишенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы унбишенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына билгеләп кую турында.
2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының вәкаләтләрен туктату турында.
3. Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларын сайлау турында.
4. «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 112-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 113-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «2021 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында» 115-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. «Пенсиягә федераль социаль өстәмә күләмен билгеләү өчен 2021 елга Татарстан Республикасында пенсионерның яшәү минимумы күләмен билгеләү турында» 114-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

8. Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе урынбасарын билгеләп куюю турында.

9. «2021 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 116-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. «2021 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 117-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 110-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасы Җир кодексының 9 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 109-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасы закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 111-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

14. Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең имин тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе мәгълүматы.

15. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты составындагы үзгәреш турында.

16. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 284 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Хакасия Республикасы Югары Советының закон чыгару инициативасы хакында.

17. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә физик затларның салым чорында 5 миллион сумнан артып киткән керемнәренә салым салу өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 1022669-7 номерлы федераль закон проекты хакында.

18. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә Россия Федерациясенең бюджет, салым һәм таможня-тариф

сәясәте төп юнәлешләренең аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 1022670-7 номерлы федераль закон проекты хакында.

19. «112» бердәм номеры буенча экстрен оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 1010252-7 номерлы федераль закон проекты турында.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2020 елның 24 сентябре
№ 599-VI ДС